# ХӨСӘЕН ФӘЕЗХАНОВ – ФӘННИ ЧЫГАНАКЛАРДА

***Исламов Р.Ф.,*** *филология фәннәре докторы,*
***Габделхакова Г.М.***

# KHUSAIN FAIZKHANOV IN SCIENTIFIC LITERATURE

***Islamov R.F., Gabdulkhakova G.M.***

Мәгълүм булганча, XIX йөз урталары – гомумрәсәй күләмендә иҗтимагый-сәяси, социаль-икътисади, рухи-мәдәни хәятнең яңарыш һәм үзгәрешләргә таба борылыш алган чоры. Татар җәмгыяте үсеше тарихында ул җәдитчелек дәвере буларак билгеле. Тарихчы, Шәрык белгече, тел галиме, педагог, каллиграф Хөсәен Фәезханов (1828–1866) – шул заманда ислах мәйданына чыккан шәхесләрнең берсе.

Х. Фәезхановның тормышы һәм фәнни эшчәнлеге, мәгълүм Октябрь түнтәрелешенә кадәр үк өйрәнелә башлап, хәзерге вакытка кадәр дәвам иттерелә. Аның концептуаль проблемалары Ш. Мәрҗани (1818–1889), В.В. Вельяминов-Зернов (1830–1904), Н.И. Веселовский (1848–1918), К.Г. Залеман (1849–1916), Р. Фәхретдинов (1859–1936), Җ. Вәлиди (1887–1932), Г. Ибраһимов (1887–1938), Г. Сәгъди (1889–1956), Ә.-З.Вәлиди (1890–1970), Н.К. Мөхетдинов (1892–1937), М.Х. Гайнуллин (1903–1985), Ә.Х. Маргулан (1904–1985), Я.Г. Абдуллин (1920–2006), В.М. Горохов (1933–2021), М.Г. Госманов (1934–2010), Ф.С. Сафиуллина (1938–2011), С.М. Михайлова (1942–2007), Я.И. Ханбиков, Р.Ф. Мәрданов һ.б.ның хезмәтләрендә чагылыш тапты.

Филология фәннәре кандидаты, археограф Р. Мәрданов үзенең бер мәкаләсендә: «Хөсәен Фәезханов гыйльми мирасының саллы бер өлешен тәшкил иткән бу табышларны галимнең башка хезмәтләре белән бергә туплап нәшер итү – нәүбәттәге бурычларыбызның берсе»[1], – дип язган иде. Аның үзе тарафыннан төзелеп, 2006 елда «Җыен» фонды тарафыннан нәшер ителгән «Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык»[2] бу юнәлештә соңгы вакытларда башкарылган зур хезмәтләрнең һәм аерым казанышларның берсе булып тора. «Шәхесләребез» сериясендә нәшер ителүче басмаларга куелган таләп нигезендә җыентыкта әүвәл Х. Фәезханов хезмәтләренең, аерым алганда, «Ислахы мәдарис» («Мәдрәсәләр реформасы»), «Рисалә» («Трактат»), «Казан тарихы», «Касимский ханлыгы», [«Борынгы Болгар ташлары»]ның төп текстлары һәм аларның хәзерге татар әдәби теленә тәрҗемәләре китерелә.

Ш. Мәрҗанигә 1860 елда язган хатында берникадәр яңгыраш алган,

әүвәлдә галимнең китапханәсендә булып, соңыннан янгын казасында юкка чыккан дип исәпләнелгән «Ислахы мәдарис» һәм «Рисалә» дигән хезмәтләрне хәзрәт оныгының кызы Нәҗия Ильясова (1919–?) белән улының оныгы Даниял Әмирханов 1986 елда тарихчы М. Госмановка китереп тапшыра. Шулай итеп, «Үзе эзләп килгән табыш» турында мәгълүмат матбугатта игълан ителә[3]. Бу ядкярләр хәзерге вакытта Казан (Идел буе) федераль университеты Н. Лобачевский исемендәге Фәнни китапханәсенең Шәрык кулъязмалары бүлегендә 4371 т., 4372 т. номерлары белән саклана.

Үз вакытында «Ислахы мәдарис»тан Г. Ибраһимов та хәбәрдар булган. Бу хакта ул 1925 елда болай дип яза: «Аның әле һаман да басылмаган «Ислахы мәдарис» исемендә китабы бар; ул иске мәдрәсәләрне яраксыз табып, шул 60 нчы елларда ук мәдрәсәләрне ислах турында проект чыгара... Ләкин фикер сүнмәде, мәдрәсәләрне ислах мәсьәләсе 70–80 нче елларда алдынгы элементларның фикерендә булып, 90 нчы елларда гамәлгә куела башлады. «Хөсәения», «Бубый», «Мөхәммәдия», соңыннан «Галия»ләр кебек, татар буржуазиясенең иң нык реформага нигезләнгән мәдрәсәләре – менә шул 60 нчы елның программасын тормышка кертү иде»[4]. Татар әдәбияты галиме г. Сәгъди сүзләрендә дә шуңа охшаш фикер уздырыла: «...1995 нче елгы революциядән соң гына гамәлгә ашыру мөмкин булган урта мәктәпләр, мәдрәсәләр реформасын күтәреп чыкты»[5].

Х. Фәезхановның җыентыкта урын алган «Касимский ханлыгы», «Казан тарихы», [«Борынгы Болгар ташлары»], «Укыту ысулы» хезмәтләре, Р. Мәрданов тарафыннан табылып, 2002 елда ук матбугатта игълан ителә[6]. Алар шулай ук Д. Әмирхановта да сакланган булган. Бу ядкярләр хәзерге вакытта Татарстан Милли китапханәсенең Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегендә 1949 т., 965 т шифрлары белән саклана. Җыентыкта ул кулъязмаларга тәфсилле тасвирлама ясалган.

Болардан тыш, күләмле булу сәбәпле җыентыкта урын алмаса да, Х. Фәезхановның 1862 елда Санкт-Петербургта нәшер ителгән «Краткая учебная грамматика татарского языка» дәреслеген дә[7] искә алып үтәргә кирәк. Академик К.Г. Залеманның «Русский биографический словарь» хезмәтенең 21 нче томында Х. Фәезхановка багышланган махсус мәкаләсендә аның Санкт-Петербургтагы эшчәнлеге, аралашкан кешеләре, галимнең студентлар өчен уку әсбабы сыйфатында рус телендә басылган бу китабы да, В.В. Вельяминов-Зернов тарафыннан нәшер ителгән «Материалы по истории Крымского ханства, извлеченные по распоряжению Императорской Академии наук из Московского главного архива Министерства иностранных дел»[8] хезмәте дә телгә алына[9].

Билгеле булганча, Х. Фәезханов 1858 елда, Россия Фәннәр академиясе тәкъдиме белән Чит ил эшләре министрлыгының Мәскәү баш архивында шөгыльләнеп, Кырым ханлыгының Россия һәм Польша белән мөнәсәбәтләре тарихына кагылышлы күп документларны өйрәнә һәм аларны күчереп ала. Алар югарыда искә алынган хезмәткә нигез

булсалар да, күренә ки, аның исеме белән нәшер ителмиләр.

Тарихчы Әхмәтзәки Вәлидинең «Шура» журналының 1912 елгы 16 нчы санында басылган «Хөсәен әфәнде Фәезхановның тәрҗемәи хәленә гаид әрбирләр» дигән мәкаләсендә әлеге уку әсбабы түбәндәгечә бәяләнә: «Бу әсәр мотлакан тәкълид юлы илә булмыйча, тәфтиш юлынча язылганлыгы һәм күп җәһәттән дөрестлеге вә бик ыксым (озын да, кыска да түгел) булганлыгы өчен татарча сарыф (морфология) китаплары эчендә мөһим урынны шөгыльләндерә»[10]. Ф.С. Сафиуллина бу уку әсбабы турында: «Г. Мәхмүдов грамматикасы нигезендә язылган үз грамматикасын Х. Фәезханов, һәр темадан соң бик күп мисаллар китереп, студентлар белән гамәли дәресләр үткәрү өчен яраклаштырган»[11], – дип яза.

Х. Фәезханов – татар эпитафия язмаларын өйрәнүгә саллы өлеш керткән галимнәрнең берсе. Мәсәлән, аның җыентыкта урын алган «Три надгробных Булгарских надписи» дигән мәкаләсе 1863 елда Император археология җәмгыяте «Хәбәрләр»енең 4 нче томында басылып чыга[12]. «Хәбәрләр»нең хәзерге вакытта сирәк чыганаклардан берсе булганлыгын истә тотканда, бу мәкаләнең биредә ни өчен урнаштырылуы аңлашыла булса кирәк. Әлеге мәкаләгә һәм болгар кабер ташларын өйрәнүдә ул тәкъдим иткән яңа методологиягә заманында тюрколог Н.И. Ашмарин (1870–1933) да туктalып үтә һәм бу уңайдан болай дип яза: «Фәезхановның мәкаләсе бик зур әһәмияткә ия, чөнки ул болгар эпитафияләренә дөрес караш урнаштыруга этәргеч бирде һәм без анда чуваш теле ярдәмендә болгар язмаларын уңышлы гына аңлату омтылышы күрәбез. Болгар язмаларының Фәезханов тарафыннан тикшерелүе нәтиҗәсендә эпитафияләрнең Березин (шулай ук Клапрот) тәрҗемәләре бик үк дөрес башкарылмаган булуы ачыклана»[13]. Бу мәкаләгә Ә.-З.Вәлиди дә игътибар итә.

Китапта Х. Фәезханов өйрәнгән 24 кабер ташы турында мәгълүмат китерелә. Алар Тәтеш өязе Байтирәк, Олы Яльчик, Аксу, Янбакты авылларында һәм аларның якын тирәләрендә табылган. Биредә шулай ук Әтрәч, Шонгаты авылларында да 21 таш барлыгы хәбәр ителә.

Аңлашылганча, Байтирәк авылындагы чиркәү ишегалдына, каравыл өе, пономарь капкасы бусагаларына, Янбакты авылы чиркәве нигезенә салынган мөселман кабер ташларын күрү галимнең күңелен әрнетә. Димәк, мондый вандализм Болгар шәһәрендәге һәм Казан Кремле эчендәге чиркәүләргә генә хас булмаган. Бу, гомумән, типик характердагы җаһил күренеш булган.

Мәгълүм хезмәттә Х. Фәезханов тарафыннан Ш. Мәрҗанигә (32), авылдашы Хәбибулла Сафаҗайга (1), Б.А. Дорнга (1805–1881) (фарсы телендә – 5), И.И. Ильминскийга (1822–1891) (татар телендә – 2), Чокан Вәлихановка (1835–1865) (татар телендә – 2), П.И. Пашинога (1836–1891) (рус телендә – 1), В.В. Григорьевка (1816–1881) (татар телендә – 1) атап язылган, үзенә Бохарадагы танышы язган (1) хатлар, шулай ук Ш. Мәрҗанинең Фәннәр академиясенә (1) һәм Кәлимулла исемле кешегә (1) хатлары (барлыгы 47 хат) тупланган.

Бу хатларның икесе танылган дин белгече, тарихчы, педагог, журналист Ризаэтдин Фәхретдиновның 1908 елда басылып чыккан «Асар» исемле биобиблиографик характердагы хезмәтенең икенче җилде, ундүртенче кисәгендә Х. Фәезхановның биографиясе белән бергә[14], тагын 25е «Шура» журналының 1916 елгы саннарында дөнья күрә[15]. Соңгылары турында ул болай аңлата: «Аның мәктүпләрене без «Асар» басылганнан соң гына күрдек»[16].

Дөрес, Бохарадагы танышы язган хат Х. Фәезхановның «Краткая учебная грамматика татарского языка» дәреслегендә үк урнаштырылган була. Аннары аны Ә.-З.Вәлиди, шуннан алып, инде күрсәтелгән мәкаләсендә бернинди үзгәртүләрсез «тәмам үз имлясы илә» бастыра[17].

Х. Фәезхановның казакъ галиме, мәгърифәтче Ч. Вәлихановка язган ике хатын шәркыятьче Г.Н. Потанин (1835–1920) 1895 елда таба һәм аларның күчермәләрен ала. Соңыннан аның архивыннан алып, казакъ академигы Ә.Х. Маргулан 1965 елда «Қазақ әдебиеті» газетасында[18] һәм Казакъстан ССРы Фәннәр академиясенең «Хәбәрләр»ендә[19] бастыра. Шул ук елда татар язучысы С. Шакир (1924–1998) тарафыннан «Қазақ әдебиеті» газетасыннан алынып, «Социалистик Татарстан» газетасында татар әдәби телендә дөнья күрә[20].

Х. Фәезхановның хатларына алга таба тарихчы, академик М.Г. Госманов мөрәҗәгать итә. М.Г. Госманов – Х. Фәезхановның тормышын һәм эшчәнлеген этрафлы өйрәнгән галимнәрнең берсе. Ул әлеге күпкырлы шәхеснең авылдашы Хәбибулла Сафаҗайга, И.И. Ильминскийга, Б.А. Дорнга, П.И. Пашинога, В.В. Григорьевка, Ш. Мәрҗанигә язган хатларының текстларын «Казан утлары» журналында[21], кайберләрен, рус теленә тәрҗемә итеп, «Заветная мечта Хусаина Фаизханова»[22] китабында бастыра. М.Г. Госмановның 1980 елда рус телендә дөнья күргән бу китабы – мәгърифәтче галим тормышы һәм эшчәнлегенең төп этапларын тәфсилле һәм этрафлы яктыртуга багышланган хезмәтләрнең берсе.

Җыентыкта Х. Фәезхановның тормышы һәм эшчәнлегенә караган 27 архив документы урын алган. Аларның тугызы укучылар игътибарына беренче мәртәбә тәкъдим ителә, калганнары исә тулысынча яки өлешчә М. Госмановның югарыда күрсәтелгән китабында китерелә[23]. Болар шулай ук кыйммәтле чыганаклар булып тора.

М.Г. Госманов «Казан утлары» журналының 1966 елгы 9 нчы санында галимнең Ш. Мәрҗанигә язган хатларына анализ ясый[24]. Шул ук журналның 1971 елгы 3 нче санында бастырган икенче мәкаләсендә Х. Фәезхановның төрле кешеләргә юллаган хатлары турында яза[25]. Биредә ул аның басма матбугат чыгару өчен иҗтиһад итүенә басым ясый. Журналның 1978 елгы 9 нчы санына Х. Фәезханов эшчәнлегенә карата аналитик характердагы мәкалә багышлый һәм Б.А. Дорнга язган ике, П.И. Пашинога, В.В. Григорьевка, Ш. Мәрҗанигә юллаган өч хатының текстларын урнаштыра[26].

М.Г. Госманов «Советская тюркология» журналының 1979 елгы 3 нче санында Г. Галимова белән автор-

дашлыкта бастырган мәкаләсендә Х. Фәезхановны тюрколог буларак ача[27]. Аеруча аның казакь теле һәм фольклоры мәсьәләләренә багышланган хезмәтләре зур кызыксыну уята. Мәкалә авторларының шәркыятьче-тюрколог Л.З. Будаговның (1812–1878) ике томлы «Сравнительный словарь турецко-татарских наречий со включением употребительнейших слов арабских и персидских» хезмәтендә Х. Фәезхановның 1863–1866 елларда казакълар арасында йөреп туплаган лексик материалларының чагылыш табуы ихтималын искәртүләре дә урынлы: алар аны галимнең Ч. Вәлихановка язган хатлары нигезендә дәлиллиләр.

Х. Фәезханов турында 2006 елда чыккан мәгълүм җыентыкта аның тормышы һәм эшчәнлеге турында галимнәрнең һәм якташларының 30 мәкаләсе урнаштырылган. Авторлар арасында Ш. Мәрҗани, К.Г. Залеман, В. Вельяминов-Зернов, Н. Веселовский, Р. Фәхретдинов, Ә.-З.Вәлиди, Ш. Шәрәф, Г. Гобәйдуллин, М. Госманов һ.б. бар.

Х. Фәезханов якташларының китапта урын алган мәкаләләре безгә хәзерге вакытта аның исемен мәңгеләштерү юнәлешендә башкарылган эшләр хакында мәгълүмат алу мөмкинлеге бирә. Әйтик, аның каберенә истәлек ташы һәм чардуган куелу, Сафаҗай мәктәбенә, авыл урамына аның исеме бирелү, 2004 елдан бирле «Фәезханов укулары» уздырылу шуңа дәлил булып тора. (Бу «укулар» башланып кына киткән вакытта мәкалә авторларының берсенә – Р.Ф. Исламовка да анда катнашу насыйп була).

Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтәргә кирәк, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе Ш. Мәрҗани исемендәге институтның мәгарифне өйрәнү бүлеге Х. Фәезханов исемен йөртә. Аның тууына 190 ел тулу уңае белән бүлек хезмәткәрләре махсус фәнни җыентык та бастырып чыгарды[28].

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Х. Фәезхановның тормышын һәм эшчәнлеген өйрәнү ирешелгәннәр белән генә тукталып калырга тиеш түгелдер. Югарыда тикшерелгән чыганаклардан күренгәнчә, алда башкарасы эшләр әле байтак.

**Сведения об авторах:** Исламов Рамил Фанавиевич, доктор филологических наук, главный научный сотрудник Центра энциклопедистики Института Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, e-mail: usman.58@mail.ru; Габдулхакова Гульшат Мансуровна, научный сотрудник Центра изучения татарской диаспоры Института Татарской энциклопедии и регионоведения АН РТ, e-mail: sofa-hakova69@mail.ru.

**Аннотация.** В статье анализируются источники о жизни и деятельности известного татарского историка, востоковеда, языковеда, педагога и каллиграфиста Хусаина Фаизханова (1828–1866). Основным объектом исследования является книга «Хусаин Фаизханов: историко-документальный сборник», изданная в 2006 г.

**Ключевые слова:** Хусаин Фаизханов, Ш. Марджани, К.Г. Залеман, Р. Фахретдинов, г. Ибрагимов, М.Г. Усманов, Р.Ф. Марданов, «Ислахы мадарис», «Рисала».

**Abstract.** The article analyzes the literature on the life and work of the famous Tatar historian, orientalist, linguist, teacher and calligrapher Khusain Faizkhanov (1828–1866). The

main object of the research is the book «Khusain Faizkhanov: historical and documentary collection», published in 2006.

**Key words**: Khusain Faizkhanov, Sh. Marjani, K.G. Zaleman, R. Fahretdinov, G. Ibragimov, M.G. Usmanov, R.F. Mardanov, «Islahi Madaris», «Risala».

## ИСТОЧНИКИ И ЛИТЕРАТУРА

1 Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 133.

2 Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / фәнни мөх. М. Госманов, төз.-авт. Р. Мәрданов. – Казан: Җыен, 2006. – 704 б.

3 Госманов М. Үзе эзләп килгән табыш // Каурый каләм эзеннән: Археограф язмалары. Тулыл. икенче басма. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – Б. 301–308.

4 Ибраһимов Г. Революциягә хәзерлек ничек булды? // Әсәрләр: сигез томда / редколлегия: Хәсәнов М.Х. (пред.), Юзиев Н.Г., Хәйруллин Х.Ф., Гайнанов Р.Р., Гыйльманов Җ.И., Зәкиев М.З., Мәхмүтова Л.Т., Мөхәррәмов М.К. (томның фәнни редакторы), Шамов А.Ш; томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче Алишев С.Х. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – Т. 7: Тарихи хезмәтләр (1911–1927). – Б. 264.

5 Сәгъди г. Татар әдәбияты тарихы: дәреслек-кулланма. – Казан: Татар. дәүләт нәшр., 1926. – Б. 62.

6 Мәрданов Р. Тарих битләрен актарганда... // Казан утлары. – 2002. – № 3. – Б. 133; Мәрданов Р. Хөсәен Фәезхановның яңа табылган «Казан ханлыгы» хезмәте турында // Проблемы истории Казани: современный взгляд: сб. ст. – Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2004. – С. 216–220.

7 Краткая учебная грамматика татарского языка (Составленная муллою Хусаином Фейз-Хановым). – СПб., 1862. – 95 с.

8 Материалы по истории Крымского ханства, извлеченные по распоряжению Императорской Академии наук из Московского главного архива Министерства иностранных дел. Издал: В.В. Вельяминов-Зернов, действительный член Императорской Академии наук. – СПб., 1864. – XI+941 с.

9 К.З. Мулла Хусейн Фейз-Ханов // Русский биографический словарь. – Т. 21: Фабор-Цявловский. – СПб., 1901. – С. 37.

10 Әхмәдзәки Вәлиди. Хөсәен әфәнде Фәезхановның тәрҗемәи хәленә гаид әрбирләр // Шура. – 1912. – № 16. – Б. 494.

11 Сафиуллина Ф. Хусейн Фейзханов // Хөсәен Фәезханов: тарихи-документаль җыентык / фәнни мөх. М. Госманов, төз.-авт. Р. Мәрданов. – Казан: Җыен, 2006. – С. 552.

12 Три надгробных надписи чл.-сотр. Муллы Хусейна Фуйз-ханова (с 3-мя таблицами снимков) // Известия Императорского археологического общества. Т. 4. – СПб., 1863. – С. 395–404.

13 Ашмарин Н.И. Болгары и чуваши // Известия общества археологии, истории и этнографии при императорском Казанском университете. Т. XVIII. Вып. 1, 2 и 3. – Казань: Типо-литогр. Имп. Казан. ун-та, 1902. – С. 69.

14 Асар. Үз мәмләкәтемездә улан Ислам галимнәренең вә мәшһүр кемсәләрнең тәрҗемә вә табәкаларе, тарих улан вә вафатлары, вә башка әхвалләре хакында язылмыш китаптыр. Икенче җилд. Ундүртенче җөзьә. Сахибе: Ризаэтдин бине Фәхретдин. – Оренбург: «Кәримов, Хөсәенов вә шөрякәсе» паровой матбагасы, 1908. – Б. 432–442.

15 Р.Ф. Хөсәен әфәнде Фәезхан // Шура. – 1916. – № 14. – Б. 329–332; № 15. – Б. 353–354; № 16. – Б. 376–378; № 17. – Б. 401–402; № 18. – Б. 425–428; № 19. – Б. 449–551.

16 Р.Ф. Хөсәен әфәнде Фәезхан // Шура. – 1916. – № 14. – Б. 329.

17 Әхмәдзәки Вәлиди. Хөсәен әфәнде Фәезхановның тәрҗемәи хәленә гаид әрбирләр // Шура. – 1912. – № 16. – Б. 494–495.

18 Марғұлан Ә. Шоқанның жаңадан ашылған досы Хусаин Фаизханов және оның Петербордан жазған хаттары // Қазақ әдебиеті. – 1965. – 29 янв.

19 Марғұлан Ә. Шоқанның жаңадан ашылған досы Хусаин Фаизханов және оның Петербордан жазғ ан хаттары // Изв. АН КазССР. Серия общественных наук. – 1965. – Вып. 3. – Б. 12–24.

20 Шакир С. Дуслык истәлеге (Хөсәен Фәезхановның Чокан Вәлихановка язган хатлары) // Социалистик Татарстан. – 1965. – 8 дек.

21 Госманов М. Хөсәен Фәезхан улының бер хыялы // Казан утлары. – 1971. – № 3. – Б. 174–177; Развитие просвещения и педагогической мысли татарского народа: сб. науч. тр., посвящ. 190-летию Хусаина Фаизханова / Науч. ред. Гибатдинов М.М.; сост.: Муртазина Л.Р., Абызова Р.Р. – Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2019. – С. 440–443.

22 Усманов М. Заветная мечта Хусаина Фаизханова. Повесть о жизни и деятельности. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – С. 62–63, 115, 140–141, 168–170, 171–172.

23 Там же. – С. 32, 35–36, 43–44, 47, 48, 97, 149–150, 167, 168–169, 169–170, 171–172.

24 Госманов М. Олы мирас // Казан утлары. – 1966. – № 9. – Б. 124–132.

25 Госманов М. Хөсәен Фәезхан улының бер хыялы // Казан утлары. – 1971. – № 3. – Б. 170–177.

26 Госманов М. Тарихыбызда Хөсәен Фәезханов урыны // Казан утлары. – 1978. – № 9. – Б. 149–158.

27 Усманов М., Галимова Г. Хусаин Фаизханов как тюрколог // Сов. тюркология. – 1979. – № 3. – С. 38–47.

28 Развитие просвещения и педагогической мысли татарского народа: сб. науч. тр., посвящ. 190-летию Хусаина Фаизханова / Науч. ред. Гибатдинов М.М.; сост.: Муртазина Л.Р., Абызова Р.Р. – Казань: Ин-т истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2019. – 160 с.